ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**15.12.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3511**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 740 номерлы карары белән расланган, Муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе мәгълүмати-методик тәэмин итү бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы боерыгы белән расланган “Татарстан Республикасы “исеме” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының “муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге)” муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының **2025 елның 05 ноябрендәге** под-1344/25 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы боерыгы белән расланган “Татарстан Республикасы “исеме” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының “муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге)” муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының **2025 елның 22 августындагы** под-1344/25 номерлы боерыгы нигезендә, 2006 елның 22 февралендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» №15-ЗТР Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы икенче өлешенә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы 740 номерлы карары белән расланган, Муниципаль берәмлекләр мәгариф педагогик хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе мәгълүмати-методик тәэмин итү бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә ( 2024 елның 21 октябрендәге 3971 номерлы, 2025 елның 14 гыйнварындагы 25 номерлы,2025 елның 06 маендагы 1195 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмати-методик тәэмин итү бүлекләре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа атамасы | Айлык база окладı күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 24498,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 24504,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлекнең структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары;<br>Муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлекнең структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) ; | - | - | 24598,0<br>24690,0» |

1.2. Нигезләмәнең «Стимуллаштыручы характерендагы түләүләр» V бүлегенең 3.3 пунктындагы унынчы абзацында «Һөнәргә тугрылык өчен» күкрәк билгесе» сүзләрен өстәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкчесе урынбасары - Татарстан республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин